**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552) 3-44-22,факс (85552)3-44-14,E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

ПР- 266
28.12.2020

**«2020 елның 1 гыйнварыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 11 декабрендәге ПР-309 номерлы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, 02-01-07/2020 номерлы 2020 елның 30 ноябрендәге протестны карап, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елның 1гыйнварыннан халыкка күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 11 декабрендәге ПР-309 номерлы карарына кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http:/aktanysh.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче И.И.Габдулхаев

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
________________ 2020 № ____
кушымта

2020 елның 1 гыйнварыннан халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләргә тарифлар

| № т/б | Түләү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү берәмлеге өчен тариф, сумнарда |
|---|---|---|---|
| | | | Актаныш күпфатирлы йортлары |
| | **Торак бина өчен түләү** | | |
| 1 | Торак йорт белән идарә итү | кв.м./сум | 3,15 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру | кв.м./сум | 2,46 |
| 3 | Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | кв.м./сум | 3,05 |
| 4 | Сантехчелтәрләрне агымдагы ремонтлау | кв.м./сум | 1,64 |
| 5 | Җылылык челтәрләренә агымдагы ремонт | кв.м./сум | 1,41 |
| 6 | Электр белән тәэмин итү челтәрләренә агымдагы ремонт | кв.м./сум | 0,92 |
| 7 | Дератизация | кв.м./сум | 0,19 |
| 8 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә хезмәт күрсәтү | кв.м./сум | 0,28 |
| 9 | Торак йортны карап тотуга электр белән тәэмин итү | кв.м./сум | 0,68 |
| 10 | Йорт эчендәге вентиляция каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | кв.м./сум | 0,25 |

Муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен база ставкасы (наем өчен база ставкасы)

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сум) |
|---|---|---|
| | | Актаныш күпфатирлы йортлары |
| Найм буенча база ставкасы | аена торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. | 6,11 |

**Торак биналарның милекчеләренә капиталь ремонт өчен түләү күләме**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сум) |
|---|---|---|
| | | Актаныш күпфатирлы йортлары |
| Капиталь ремонт | аена торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. | 6,11 |

**Актаныш муниципаль районы буенча сыек көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәт күрсәтүнең тәкъдим ителә торган бәясе**

| Түләү атамасы | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен база ставкасы (сум) |
|---|---|---|
| | | Актаныш күпфатирлы йортлары |
| Торак-көнкүреш калдыкларын чыгару | аена /кеше | 100 |